ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.07.2024 Олы Кайбыч ав. № 250

Күпбалалы гаилә статусы билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә, күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында» 2024 елның 18 июнендәге 20-09/8480 номерлы хатына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә, күпбалалы гаиләләргә ташламалар бирелгәндә, федераль дәрәҗәдә бердәм таныклык үрнәге билгеләнгәнче, балалар туу турында таныклык яисә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын билгеләү турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгы белән расланган күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында карар нигезендә ташламалар һәм хезмәтләр күрсәтергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров